КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 июль г.Казань № 560

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар турында» 2015 ел, 5 июнь, 418 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар турында» 2015 ел, 5 июнь, 418 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләгәндә, үзгәрткәндә, аның эшчәнлеген туктатканда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының башка органнар һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен;»;

әлеге карар белән расланган Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округлары турындагы нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләгәндә, үзгәрткәндә, аның эшчәнлеген туктатканда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының башка органнар һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге тәртибе»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру

җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләгәндә, үзгәрткәндә, аның эшчәнлеген туктатканда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының башка органнар һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге механизмын билгели.»;

8 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округлары проектына бу зона чикләре турындагы мәгълүматлар мәҗбүри теркәлергә тиеш, аларда бу зона чикләре урнашу урынының график тасвирламасы, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән координатлар системасында бу чикләрнең характерлы нокталары координатлары исемлеге булырга тиеш.»;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария саклык округы проекты гариза бирүче тарафыннан кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу, дәүләт санитария-эпидемиология кагыйдәләрен һәм гигиена нормативларын эшләү һәм раслау, шулай ук кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген һәм федераль дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән турыдан-туры йә аның территориаль органы белән килештерелә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кертелә.

Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның тау санитариясе саклык округы проекты гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу, дәүләт санитария-эпидемиология кагыйдәләрен һәм гигиена нормативларын эшләү һәм раслау, шулай ук кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген һәм федераль дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән турыдан-туры йә аның территориаль органы белән килештерелә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кертелә.

Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округы проекты Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы территорияләрне төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар дип тану мәсьәләләре буенча ведомствоара эксперт советы (алга таба – эксперт советы) тарафыннан 30 көн эчендә карап тикшерелә.

Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округы проектын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча эксперт советының уңай бәяләмәсендә (алга таба – уңай бәяләмә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аларны урнаштыруга бәйле рәвештә яки аларны саклау һәм саклап калу

максатларында төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округы билгеләнә торган объектның, территориянең исеме, төре, мондый объектларның, территорияләрнең адресы яки урнашу урыны. Яңа төзелә торган капиталь төзелеш объектын урнаштыруга бәйле рәвештә, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләгән очракта, уңай бәяләмәдә капиталь төзелеш объектының исеме аның проект документлары нигезендә һәм мондый объект төзергә планлаштырыла торган җир кишәрлегенең адресы күрсәтелә;

2) җир кишәрлекләреннән файдалануның төгәл чикләүләре;

3) ярдәмче зоналар, аларның саны турында мәгълүматлар, һәр ярдәмче зона чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдалануның төгәл чикләүләре;

4) бинаның, корылманың хокукка ия булучысы, төзүче турында, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләүгә, үзгәртүгә бәйле рәвештә салынган зыяннарны капларга бурычлы дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы турында мәгълүматлар;

5) зыяннарны каплау йөкләмәсен үти башлау вакыты.

Эксперт советының уңай бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аны раслаган көннән 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләү, үзгәртү, аның эшчәнлеген туктату турындагы норматив хокукый акты проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләү, үзгәртү, аның эшчәнлеген туктату турындагы норматив хокукый акты проекты Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан территорияләрендә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округы урнашкан муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары белән килештерелә.

Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җиренең һәм курортның санитария һәм тау санитариясе саклык округы проектын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча эксперт советы тискәре бәяләмә биргән очракта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан ул расланган көннән өч эш көне эчендә материаллар эксперт советы бәяләмәсе белән гариза бирүчегә кире кайтарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $18^1$ – $18^{11}$ нче пунктлар өстәргә:

«$18^1$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләү, үзгәртү, аның эшчәнлеген туктату Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

$18^2$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең

һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын үзгәртү турындагы карарда зона, аның ярдәмче зоналары чикләрен үзгәртү турында мәгълүматлар, территориядән файдалану буенча махсус шартлары булган әлеге зонаны билгеләү турындагы карар белән күздә тотылган һәм күрсәтелгән чикләүләрдән аерыла торган әлеге зона, аның ярдәмче зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен файдалану чикләүләре күрсәтелә.

$18^3$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләү турындагы карарга, шулай ук бу зонаның чикләрен үзгәртүне күздә тота торган төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын үзгәртү турындагы карарга мәҗбүри кушымта булып бу зона чикләре урнашу урынының график тасвирламасы, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән координатлар системасында бу чикләрнең характерлы нокталары координатлары исемлеге бирелгән әлеге зона чикләре турында мәгълүматлар тора. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләре урнашу урынының график тасвирламасы формасы, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләренең характерлы нокталары координатларын билгеләү төгәллегенә, әлеге мәгълүматлар бирелгән электрон документ форматына карата таләпләр Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару, күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алуны, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

$18^4$. Бу Тәртипнең $18^3$ нче пунктында каралган төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләре турындагы мәгълүматларны әзерләү биналар, корылмалар урнаштыруга бәйле рәвештә тиешле зоналары билгеләнә яки үзгәртелә торган әлеге биналар, корылмалар милекчеләре тарафыннан (мондый биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү (файдалану) аларның предметы булып торган концессион килешү, дәүләт-хосусый партнерлык турындагы килешүләр, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләр гамәлдә булган чорда (әгәр дә башкасы әлеге килешүләр белән каралмаган булса) концессионер, хосусый партнер тарафыннан), мондый биналарның, корылмаларның башка хокукка ия булучысы тарафыннан (әгәр дә бу йөкләмә аның тарафыннан әлеге биналарга, корылмаларга ия булу һәм (яки) аларны файдалану гамәлгә ашырыла торган документта каралган булса), төзергә планлаштырыла торган объектны урнаштыруга бәйле рәвештә, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы зонасын билгеләү очрагында төзүчеләр тарафыннан, хокукка ия булучысы, төзүчесе булмаганда яки биналар, корылмалар урнаштыруга бәйле булмаган нигезләр буенча төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм

курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләгән очракта, гариза бирүче тарафыннан тәэмин ителә.

$18^{5}$. Әгәр дә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләрендә ике яки аннан күбрәк ярдәмче зоналар бүлеп чыгарылса, мондый зоналарның чикләре турындагы мәгълүматлар бу Тәртипнең $18^{3}$ һәм $18^{4}$ нче пунктлары нигезендә әзерләнә, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләү турындагы карарга яки мондый ярдәмче зоналарның чикләренә үзгәреш кертүне күздә тота торган төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округына үзгәреш кертү турындагы карарга мәҗбүри кушымталар булып тора һәм төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләре урнашу урыны турындагы мәгълүматлар составына кертелә.

$18^{6}$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы эшчәнлеген туктату турындагы карарда бу зонаның эшчәнлеген туктату һәм бу зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалану чикләүләренең гамәлдә булуын туктату турында мәгълүматлар күрсәтелә.

$18^{7}$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округын билгеләү, үзгәртү, аның эшчәнлеген туктату турында карар кабул иткән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге карарның күчермәсен яки төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләре турындагы мәгълүматларны территорияләрендә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы билгеләнгән шәһәр округының, җирлекнең җирле үзидарә органына (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлегенең төбәк системаларын файдаланып) җибәрә.

$18^{8}$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм анда урнашкан объектларның хокук ияләренә теркәү органы тарафыннан төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы хакындагы мәгълүматларны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү яки мондый мәгълүматларга үзгәрешләр кертү турында хокукларны «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителергә тиеш. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләре җирлектә махсус билгеләр белән (әгәр дә җир кишәрлегененең хокук иясе мондый билгеләрне урнаштыру өчен җир кишәрлегенә керү мөмкинлеге белән тәэмин ителмәгән очраклардан тыш)

билгеләнергә тиеш. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләрендә ярдәмче зоналар билгеләнгән очракта, аларның чикләрен җирлектә билгеләү (әгәр дә федераль закон белән башкасы каралмаган булса) таләп ителми.

$18^9$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы чикләнмәгән вакытка яки билгеле бер вакытка билгеләнә. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы билгеле бер вакытка билгеләнгән очракта, күрсәтелгән вакыт узганнан соң, бу зонаның эшчәнлеге туктатыла, бу очракта төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү таләп ителми.

$18^{10}$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы җирләрнең категориясенә һәм җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләренә карамастан билгеләнә.

$18^{11}$. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы, мондый зоналардагы җир кишәрлекләрен файдалану чикләүләре Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы турындагы мәгълүматлар, мондый зоналар хакындагы мәгълүматларга тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән билгеләнгән, үзгәртелгән дип санала. Төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләренең һәм курортларның санитария һәм тау санитариясе саклык округы турындагы мәгълүматлар Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылган көннән эшчәнлеген туктаткан, ә мондый зоналардагы җир кишәрлекләреннән файдалануны чикләүләр гамәлдә түгел дип санала, әгәр дә федераль закон белән башкасы каралмаган булса.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин